| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Менделеевский муниципальный район**<br>**Исполнительный комитет**<br>**Татарско-Челнинского сельского поселения** | **Татарстан Республикасы**<br>**Менделеев муниципаль районы**<br>**Татар-Чаллысы авылы җирлеге башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**28 июль 2026 ел** **№ 38**

Менделеевск муниципаль районының
“Татар Чаллысы авыл җирлеге” муниципаль
берәмлеге территориясендә стационар булмаган
сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын кушымта нигезендә расларга.

2. Биш көн эчендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруның күрсәтелгән схемасын Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына тапшырырга.

3. Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында" 2013 елның 24 октябрендәге 12 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны җәмәгать урыннарындагы мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында “Татар Чаллысы авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам

Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы Т.П. Кузнецова.

2026 елның 28 июлендәге 38 нче номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № | Стационар булмаган сәүдә объектларының урнашу урыны исеме | Сатыла торган товар ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объектлары тибы (павильон, | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының стационар булмаган сәүдә объектларыннан | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру чоры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Татар Чаллысы авылы, Җиңү ур. № 2 йорт янында | Кием-салым, аяк киеме, хуҗалык товарлары һәм бакча җиһазлары, уенчыклар, Үсентеләр һәм орлыклар, тере кош-корт, кош һәм терлек азыгы, кондитер эшләнмәләре, ассортиментта ит, йомырка, сөт продуктлары, казылык эшләнмәләре, сырлар, ассортиментта балык, яшелчә һәм җиләк-җимеш, кипкән җиләк-җимеш | Автолавкалар | әйе | Атна саен шимбә көннәрендә 7 сәг. 14 сәг. кадәр. |
| 2 | Татар Чаллысы авылы, Җиңү ур. авыл мәдәният йорты | Балалар уенчыклары, кондитер эшләнмәләре, | Палатка | әйе | Бәйрәм чаралары (авыл көне-19 август, балалар Сабан туе -1 июнь) |